

# ТУГАН ЯК
# РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 6 (21) 23 МАРТА 2010

РЕПОРТАЖ



## ЮБИЛЕЙ В «ЮБИЛЕЙНОМ»

В прошедшую пятницу, 19 марта, в Бугуруслане, в ДК «Юбилейный» состоялось торжественное собрание, посвященное двадцатилетию создания татарского общественного центра «Туган тел». Событие для татарской общественности города знаковое и историческое. Это и возможность вспомнить, с чего все начиналось, и осознание роли ТОЦ в современной жизни города.

Итоги работы центра подвел председатель этой общественной организации Хамзя Газизов. Он рассказал о нынешней работе ТОЦ, поблагодарил основателя центра и первого председателя Раиса Каримова, за столь важное начинание.

Много было гостей, в том числе и из Казани. Сопредседатель Совета федеральной национально-культурной автономии татар, член исполкома Всемирного конгресса татар Фарит Уразаев назвал Оренбуржье своего рода колыбелью нации, где свято берегут язык, традиции и культуру народа. Пожелание успехов и благополучия передал от пензинских татар Кязым Дебердеев — председатель татарской национально — культурной автономии этой области.

Юбиляров поздравили и соседи: председатель ТНКА Асекеевского района, депутат Законодательного Собрания Оренбургской области Ильдус Давлятов, председатель татарской общественной организации Похвистневского района, Самарской области Расих Латыпов и многие другие.

Запомнилось приветствие юбиляров от имени мордовской общественной организацией города. Ее председатель, Виктор Тингаев, зачитал приветствие на татарском языке.

После торжественной части состоялся большой концерт. Восторженно приветствовали бугурусланцы асекеевских артистов, выступления которых были понастоящему народными и талантливыми.

**На снимке:** Фарит Уразаев награждает лучших.

ВЕСТИ. СОБЫТИЯ

## Науруз пришел в наш дом

В Асекеевском районном Доме культуры, 21 марта, состоялось празднование Науруза — Нового года по солнечному календарю, совпадающего с днем весеннего равноденствия. Этот праздник распространен среди народов Казахстана, Ср. и Малой Азии, Ирана, а также среди башкир и татар. Репортаж о праздновании «Науруз бәйрәме» читайте в следующем номере газеты.

## В рамках акции — концерт

В Наурузовском сельском Доме культуры, 7 марта, в рамках акции « Помоги ребенку», состоялся большой концерт. Программу подготовили учащиеся и учителя местной школы, которые и выступили на сцене. И вполне удачно. Несмотря на то, что концерт был платным и ставили его не заезжие «звезды», а свои таланты, зрительный зал оказался полным. Селяне громкими аплодисментами поддержали каждого выступившего. Родители с удовольствием смотрели и слушали, как танцуют и поют их дети. Интересно было зрителям видеть строгих учителей в ипостаси талантливых артистов, особенно в шутливых номерах. Сбор от концерта оказался солидным. Их решено израсходовать на заказ национальных, сценических костюмов для детей-участников художественной самодеятельности.

Средств от концерта хватило еще и на призы участникам конкурса « А ну-ка, девочки!», состоявшегося 10 марта. В нем приняли участие 4 команды учащихся 5-8 классов. Победили самые находчивые, самые смелые и ловкие восьмиклассницы, выступившие в команде под весенним, солнечным названием «Веснушки».

**И.СУЛЕЙМАНОВА,**
**Пономаревский район.**

ИЗ ПИСЕМ В РЕДАКЦИЮ

## И туган тел...

Хөрмәтле редакция!

Күптән түгел генә мин, Резеда Вәлиеваның «Якты ярда калган балачак» китабын, балалар китапханәсеннән алып укыдым. Безнең Әсәкәй район мәдәният йортында өч тапкыр килеп чыгыш ясаган икән. Ниндидер сәбәп булып, мин бара алмадым һәм бик үкенәм шуның өчен. Миңа шулчаклы ошады аның язган әсәрләре. Ничек ул аңлый икән балалар психологиясен, тормышны. Китапны укып чыккач җан чистарып китте, күңел сафланды, йомшарды. «Тегe» заманда безнең халык өчен «бикләп» тотканнар исә татар язучыларының әсәрләрен. Минем буын Тукайны, Җәлилне генә белә иде. Искиткеч бездә сәләтле язучылар һәм аларның әсәрләре! Элек бит без татарча укымадык. Хәтта үзебезнең телдә сөйләшергә дә кушмыйлар иде. Хәзер татарча укырга өйрәндем һәм шулкадәр куанам үзебезнең халкыбызның бөек язучылары, шагыйрьләре белән, аларны укый алганыма. Менә шуларның берсе-Резеда Вәлиева. Укып чыкканнан соң, һәрбер әсәре уйланырга ярдәм итә. Нинди тәртип, үрнәк алырга кирәк балаларга да, олыларга да. Үзебезнең ана теленең кадерен, тәмен белеп һәм кирәк икәнен белеп яшәргә. Ә саклап калу өчен, балаларыбызга өйрәтергә кирәк, соңыннан үкенерлек булмасын иде.

Мин һичшиксез уйлап та тормыйча, Резеда Вәлиеваның китабын сатып алып түргә куйдым, кабат яңадан укырга. Барлык танышларыма киңәш бирәм: укыгыз Резеда Вәлиеваның китапларын!

**Рәйсә ШАФИЕВА,**
**Әсәкәй авылы.**

## Слово редактора

Закончился первый квартал 2010 года. Выпущены уже шесть номеров газеты в новом формате — по два ежемесячно. Это прибавило нам читателей, а главное — налаживается обратная связь. В редакцию поступает письма с пожеланиями и предложениями. Много стихов, рассказов, воспоминаний. Редакция не имеет пока возможности печатать все, что прислано нашими подписчиками, но мы постараемся никого не обойти вниманием.

Как и при создании газеты в октябре 2008 года, так и сейчас, перед редакцией стоит один главный вопрос: а нужна ли наша газета вообще? Повышение числа подписчиков, отклики читателей и их звонки — однозначно в пользу существования нашего издания, однако, может случиться так, что «Туган як» перестанет выходить из-за финансовых проблем.

Каждый экземпляр газеты нам обходится примерно в 16 рублей. По подписке же берем около 8 рублей. То есть остальные 8 пытаемся пополнять за счет спонсоров, а так же поступлений от объявлений и поздравлений. Куда уходят эти средства? Это услуги типографии, почты, дизайнера-верстальщика, содержание самой редакции. При этом надо отметить, что мы стареемся предельно экономить на своем содержании, да так, что можно с уверенностью сказать, что газета выпускается на нашем энтузиазме.

Существенной прибавкой было бы увеличение тиража газеты. Поэтому, мы просим вас, уважаемые читатели, оформить подписку на почте или у почтальонов. Привлечь своих родных, друзей, соседей. И одновременно сообщаем, что бесплатной раздачи газеты больше не будет. Сумма подписки — чисто символическая. Она не превышает стоимость бутылки пива или «Пепси Колы».

Существенные надежды возглавляем на наших соплеменников — бизнесменов. Можно, к примеру, оплатить типографские расходы или подписать на газету 100 односельчан. В ответ редакция поможет с рекламой ваших товаров и услуг.

Ваша спонсорская помощь помогла бы сохранить единственную, независимую, татарскую газету в регионе.



ИСЛАМ

# АТА — АНА ХАКЫ

**Мөселманның күркәм холыкларының берсе — ата-анага яхшы мөнәсәбәт, аларга карата изгелекләр кылу. Коръән-кәримдә һәм Пәйгамбәребезнең (гәләйһис-саләтү вәс-сәләм) хәдисләрендә ата-ананы хөрмәт итү турында бик күп әйтелә.**

Коръән-кәримдә шушы аятләрдә ата-ана хакы турында әйтелеп китә:

1. «Аль-Бакара» («Сыер» сүрәсе: аятләр 83, 180, 215);
2. «Ан-Ниса» («Хатыннар» сүрәсе: аятләр 11, 36);
3. «Аль-Әнгам» («Әнгәм» сүрәсе: аят 151);
4. «Аль-Исра» («Исра» сүрәсе: аятләр 23 — 24);
5. «Аль-Анкабут» («Үрмәкеч» сүрәсе: аят 8);
6. «Локман» («Локман» сүрәсе: аятләр 14, 15);
7. «Аль-Ахкаф» («Ком» сүрәсе: аят 15).

Ата-анага яхшы мөнәсәбәттә булуның, Аллаһыга ышану һәм Аңа гыйбадәт кылудан соң килүе турында бер шиксез әйтергә була. Аллаһы Тәгалә Коръәндә зур ширк мәсьәләсен ата-ананы хөрмәтләү мәсьәләсе берлә беркү дәрәҗәгә күтәрә, Раббыбыз ата-аналарны хөрмәт итәргә боерган: «Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһуга гына гыйбадәт кыйлыргa һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә гел, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә гел! Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәй гел! Вә әйт: «Ий Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыйл!»

Адәм баласының тормыш юлы бик тә кызыклы һәм гыйбрәтле. Дөньяга килгән сабый бернәрсә белми һәм ата-анасыннан башка бернәрсә эшләргә дә куәтле түгел. Аның ашавы-киенүе турында ата-анасы кайгырта. Шул сабый акрынлап аякка баса, яңадан-яңа шөгыльләр һәм гыйлемнәргә ирешә. Хәтта кайберәүләрнең күңелләрендә тәкәбберлек сыйфатлары да уяна. Күп очракта, үсеп җиткәч, балаларга газиз аналары кирәкми башлый һәм алар аны оны- тып җибәрәләр. Әгәр балалар үсеп җиткәч ата-ана аңа нәрсә биргәнен аңласалар, бу бик зур сөенеч. Киресенчә, әгәр аңламасалар — бик зур көенеч.

Аллаһы тәгалә әйткән: «Без кешегә ата анасына карата ихтирамлы булырга боердык. Әнисе авырлык өстенә авырлык белән аны күтәрә һәм ике елдан соң аны күкрәктән аера. Миңа һәм ата-анаңа шөкер ит, дип боердык, бит ахырда Миңа кайтасыз.» Бу коръән аятләре ата-ананың балалар алдындагы фазыйләтләре турында ачык итеп аңлатып бирә. Бигрәк тә анасының баласын тудырганчыга кадәр һәм аны тудырганнан соң булган хәле турында сөйли. Коръән ананың күрсәткән тырышлыкларын күрсәтә, ана башта баланы үзендә йөртә. Һәр көн саен карында бала үсә, авырая тора. Ананың хәле зәгыйфьләнә төшә. Соңыннан авырлык белән баланы тудыра. Әмма ана кеше бу авырлыкларга түзә. Баланы тудыргач аны имезә, көннәрен һәм төннәрен баласына багышлый. «Балам тыныч йокласын»- дип, кайбер төннәрен йокламый үткәрә. «Балам тук булсын»- дип, кайбер чакларда үзе ач кала. Ана үз балалары өчен җан атып тора. Баласы чирләсә, берәр урынын авырттырса — сызлана, аның күзенә бер нидә күренми. Әлбәттә, бу хәлләрне фәкать аналар гына белә.

Ибне Гомәр разыяллаһу ганһу бер Йемен кешесенең әнисен кулына күтәреп Кәгъба тирәли әйләнгәнен күргән. Ул кеше:» Мин аның басынкы дөясе, ул мине күтәреп йөргәннән дә, мин аны күбрәк күтәреп йөрдем. Ничек уйлысың ибне Гомәр мин аңа тиешлесен кайтардымы икән?», — дип сораган. Ибне Гомәр: «Юк, бер тулгагын (баланы тудыргандагы авырту) да кайтармадың», — дип җавап биргән.

Пәйгамбәребез (гәләйһиссаләтү вәс-сәләм) үзенең күркәм нәсыйхәтләрен җиткергәндә, кешеләргә үзләренең ата-аналарына карата, хәтта алар мөселман булмасалар да, һәрвакыт игелекле һәм яхшы мөнәсәбәттә булырга васыять итеп калдырган.

Ата-ананың хөрмәтләргә боерган бик күп хәдисләр дә табарга мөмкин. Габдуллаһ ибне Мәсгут разыяллаһу ганһу Пәйгамбәребездән (гәләйһис-саләтү вәс-сәләм): «Аллаһ иң яраткан эш нинди?», — дип сораган. Пәйгамбәребез (гәләйһис-саләтү вәс-сәләм): «Үз вакытында укылган намаз», — дип җавап биргән. Габдуллаһ: «Намаздан соң?», — дип сораган. Ул: «Ата-ананы хөрмәт итү», — дигән. Пәйгамбәребез (гәләйһис-саләтү вәс-сәләм) ата-ананы хөрмәт итүне мөселманның әһәмиятле эшләре — вакытында намаз уку белән бер сафка куйган. Кеше фарыздан кала башка ирекле намаз укыганда, әнисе яки әтисе мөрәҗәгать итсә, җавап бирергә тиеш.

Пәйгамбәребез (гәләйһиссаләтү вәс-сәләм) тагын да әйткән: «Аллаһы тәгалә каршысында әти-әнинең догасы, мосафирның һәм мазлум кешенең догасы кабул булмый калмый». Дөньяда бәхетле, ахирәттә җәннәтле буласы килсә, әтиәниебез изге догаларыннан мәхрүм булмыйк. Ата-аналарын рәнҗеткән кешеләрнең Раббыбыз үзләренеңдә догаларын кабул итми, эшләрендә уңышларын бирми.

Аллаһы тәгалә Муса гәләйһис-сәләмгә болай әйткән: «Кем әти-әнисен хөрмәт итә, Мин аның гомерен озын кылырмын, һәм аңа аны үзен хөрмәт итә торган балалар бирермен. Кем әти-әнисен рәнҗетә, аның гомерен кыска кылырмын, һәм аңа үзен рәнҗетә торган балалар бирермен.» Әгәр әти-әниләребезне рәнҗетәбез икән, каһәрлибез икән, картайган көнебездә, үзебез әти-әни булгач, шушыны күрәчәкбез. Инде әти-әниләребезне кадерлибез икән, картайган көнебездә безне дә балаларыбыз хөрмәтләр. Ата-анага каты булу, аларны карамау, аларның сүзләрен тыңламау иң бөек гөнаһларның берседер. Аллаһыга каршы кылынган гөнаһлардан соң килгән бер гөнаһтыр бу.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд (гәләйһис-саләтү вәссәләм) бер хәдис шәрифендә: «Ата-ана ризалыгы — Аллаһ ризалыгыдыр, ата-ана ачулануы — Аллаһ ачулануыдыр», — дип боера.

Ата-ананы рәнҗетүдә бик сак булыйк, чөнки бу гөнаһның әсәрләре бик зур. Аларны хөрмәт итик, алар бу дөньяны калдырып киткәч, үкенербез. Ата-аналарыбызны хөрмәт итик, сәламәт вакытларында аларга хезмәтләр кылыйк, догалары алып калырга тырышыйк. Үлгәннәреннән соң үзләрен онытмыйк, алар өчен дога кылып, изгелекләр итеп, рухларына багышлыйк. Бер вакытта нинди дер кеше Пәйгәмбәребездән (гәләйһис-саләтү вәс-сәләм)болай дип сораган: «Ий Аллаһының илчесе, мин ата-анам үлгәч аларга хөрмәт итә аламмы?» Аңарга Пәйгәмбәребез (гәләйһис-саләтү вәс-сәләм) «Дүрт төрле юл белән хөрмәт итә аласың: алар өчен дога кылып; алар вәгъдә кылган эшләрне үтәү белән; аларның дусларын хөрмәт итү белән; алрның туганнары белән элемтә тоту белән», — дип җавап биргән. Ата-анасы исән вакытта, аларның ризалыгын алган кеше, дөньяахирәт дәрәҗәсенә ирешә.

Ата-ананы хөрмәт итү намуслы һәм әдәпле кешеләрнең сыйфаты булып санала. Ата-ананы хөрмәтләү — Исламның бөек нәсыйхәте, боерыгы.

Аллаһы тәгалә һәммәбездә үзенең рәхмәтеннән, әтиәниебезнең изге догаларыннан мәхрүм итмәсен. Әмин.

**Имам ИЛДАР хәзрәт,**
**Әсәкәй мәчете.**

СЕЛЬСКИЙ СПОРТ



# На приз «Алги»

В воскресенье, 14 марта, в селе Новосултангулово, Асекеевского района, состоялся традиционный турнир по хоккею на приз ОАО «Алга». В нем приняли участие три команды. Самого акционерного общества, а так же райцентра и Бугурусланского района. Встречи велись по круговой системе, в результате, уверенную победу одержали асекеевцы. Они и получили главный денежный приз. Были так же награждены команды Бугурусланского района и «Алги», занявшие соответственно второе и третье место. Лучшим игроком признан Александр Ивкин из Асекеева.

В целом хоккеисты остались довольны турниром. Как всегда, соревнования были хорошо организованны, позаботились хозяева и о питании спортсменов.

Генеральный директор ОАО «Алга» Ильдус Давлятов, пожелал спортсменам новых побед.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

**Время летнее**



| АПРЕЛЬ | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Ойлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 7-05 | 8-05 | 15-10 | 19-10 | 21-10 | 22-40 |
| 2 | 7-03 | 8-03 | 15-10 | 19-12 | 21-12 | 22-42 |
| 3 | 7-01 | 8-01 | 15-10 | 19-14 | 21-14 | 22-44 |
| 4 | 6-58 | 7-58 | 15-10 | 19-15 | 21-15 | 22-45 |
| 5 | 6-55 | 7-55 | 15-10 | 19-17 | 21-17 | 22-47 |
| 6 | 6-52 | 7-52 | 15-10 | 19-19 | 21-19 | 22-49 |
| 7 | 6-50 | 7-50 | 15-10 | 19-21 | 21-21 | 22-51 |
| 8 | 6-48 | 7-48 | 15-10 | 19-22 | 21-22 | 22-52 |
| 9 | 6-46 | 7-46 | 15-10 | 19-24 | 21-24 | 22-54 |
| 10 | 6-43 | 7-43 | 15-10 | 19-26 | 21-26 | 22-56 |
| 11 | 6-40 | 7-40 | 15-10 | 19-28 | 21-28 | 22-58 |
| 12 | 6-38 | 7-38 | 15-10 | 19-30 | 21-30 | 23-00 |
| 13 | 6-36 | 7-36 | 15-10 | 19-32 | 21-32 | 23-02 |
| 14 | 6-34 | 7-34 | 15-10 | 19-33 | 21-33 | 23-03 |
| 15 | 6-32 | 7-32 | 15-10 | 19-35 | 21-35 | 23-05 |
| 16 | 6-29 | 7-29 | 15-10 | 19-37 | 21-37 | 23-07 |
| 17 | 6-27 | 7-27 | 15-10 | 19-39 | 21-39 | 23-09 |
| 18 | 6-25 | 7-25 | 15-10 | 19-41 | 21-41 | 23-11 |
| 19 | 6-22 | 7-22 | 15-10 | 19-42 | 21-42 | 23-12 |
| 20 | 6-20 | 7-20 | 15-10 | 19-44 | 21-44 | 23-14 |
| 21 | 6-17 | 7-17 | 15-10 | 19-46 | 21-46 | 23-16 |
| 22 | 6-15 | 7-15 | 15-10 | 19-48 | 21-48 | 23-18 |
| 23 | 6-13 | 7-13 | 15-10 | 19-49 | 21-49 | 23-19 |
| 24 | 6-10 | 7-10 | 15-10 | 19-51 | 21-51 | 23-21 |
| 25 | 6-08 | 7-08 | 15-10 | 19-53 | 21-53 | 23-23 |
| 26 | 6-06 | 7-06 | 15-10 | 19-55 | 21-55 | 23-25 |
| 27 | 6-04 | 7-04 | 15-10 | 19-56 | 21-56 | 23-26 |
| 28 | 6-02 | 7-02 | 15-10 | 19-58 | 21-58 | 23-28 |
| 29 | 6-00 | 7-00 | 15-10 | 20-00 | 22-00 | 23-30 |
| 30 | 5-58 | 6-58 | 15-10 | 20-02 | 22-02 | 23-32 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом.**
**Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**

# УРМАН КЫЗЫ (ПОЭМА)

**Пролог**

Тирә якта кара урман.
Уртасында бер авыл.
Бу авылны урман саклый
Килеп чыкса җил-давыл.
Чишмәләрдән чыккан инеш
Авылны урап ага.
Шул инештә су керәләр
Җәйләрен бала-чага.
Өйләр санына килгәндә
Егермеләп чамасы.
Күпләре инде искергән,
Берәм-сәрәм яңасы.
Хәзергесе көндә монда
Картлар гына яшәп ята.
Ара-тирә хәл белергә
Якыннары да кайта.
Сугышка кадәр авылда
Йөзләп кеше яшәгән.
Башлангыч белем алырлык
Мәктәбе дә эшләгән.
Төрледән җыелган халкы:
Кышларын урман кискән,
Җәен җиләк-җимеш җыйган,
Каен суларын эчкән.
Авыл очындагы өйдә
Урман хуҗасы торган.
Кул арасына керердәй
Үсмер кызы да булган.
Бу урманчының хатыны
Баладан үлгән диләр.
Шулай алар яшәгәннәр
Әтисе кызы белән.
Кырык беренче елларның
Дәһшәтле көннәре.
Шул урманда олыганнар
Карт бүреләр төннәрен.
Эттә бүре токымыннан
Олылар бит сөйлиләр.
Этләр бүредәй олыса
Юньлегә түгел диләр.
Шул ел җәен халкыбызга
Зур кайгы, бәлә килде.
Кетмәгәндә илебезгә
Фашистлар бәреп керде.
Каты сугышлар башлангач,
Авыл, шәһәрләр яна.
Поэманың эчтәлеге дә
Шуңа башлана.
Сугыш беткәненә инде
Хәзер ничә ел үтте.
Күпме яшьләр бу сугышта
Үзләрен корбан итте.

**Беренче бүлек**

Кояш батканда
Офык учагы
Кызарта күкне,
Матур шулчагы.
Урман өчендә
Кошлар сайраша.
Күңелгә керә
Хисләр, моң аша.
Шундый гүзәллек,
Ямьле җәйге кич.
Тирә-як чәчкә,
Онытылмас һич.
Өлгереп килә
Җиләк-җимеше.
Иренмичә җый
Кемнең юк эше.
Алан эчендә
Тавыш ишетелә.
Чиләген тотып
Бер кызый килә.
Чиләге тулган
Тирә-юньгә карана.
Бу чиксез урман
Бик таныш аңа.
Буй сыны зифа,
Сөйкемле йөзе.
Бу бит Олесья-
Урманчы кызы.
Борын астыннан
Нәрсәдер җырлый.
Битен сыпыра,
Чәчләрен тарый.
Ашыга кебек
Өйгә кайтырга.
Караңгы төшә
Урманга, кыргa.
Бераздан алда
Утлар күренә.
Олеся кайтып
Җитте өенә.

**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН**
**(Дәвамы киләсе номерда).**
**Иске Мөъмин авылы, Әсәкәй районы.**

## БӨЕК ЖИҢҮНЕҢ 65 ЕЛЛЫГЫНА



# СУГЫШ ФАҖИГАЛАРЫ

**Мин сугыш вакытындагы гади авыл кешеләре һәм үземнең гаиләгә кагылган фаҗигале вакыйгалар турында язарга булдым.**

Яшь чакта мин әнидән «Сугышка кадәр ничек тордыгыз?», — дип сораган идем. «Без бик яхшы тордык, чөнки безнең ирләребез аракы эчмиләр иде бит. Ир-ат сугыштан әчәргә өйрәнеп кайтты» — дип, җавап биргән иде.

Әчү хәзер гадәткә әверелде. Әнинең сөйләвенчә, туйларны да эчемсез үткәргәннәр. Кызык өчен, туй барганда ярышка чәй эчкәннәр. Сүз осталары төрле мәзәкләр сөйләгәннәр, җырчылар-җырлаган, биючеләр-биегән. Бик матур, шаулап үткән туйлар.

Сугыш халыкка зур имтихан да булган. Берәүләр иле, халкы өчен кызганмый сугышкан. Икенчеләре көне-төне эшләгән.

Минем абыемны авыруы булганга армиягә алмаганнар. Ул бөтен көчен дәваланугa куеп һәм терелеп, хезмәт итәргә алуларын утенеп сораган. Ниһаять аны алганнар. Аның шатлыгы шулкадәр зур булган, хәтта күпер аша әнидән сөенче алган. Ләкин аңа кайтырга, безгә күрергә насып булмады...

Арада бик юньсезләр дә булган. Безнең Иске Тирес авылында (чыгышым белән мин шул авылдан) иген бирмәгән өчен колхоз рәисен уналты җирен пычак кадап үтергәннәр. Аны үтергәннән соң, Артемовка авылында һәрбер йортка кереп толыпларын сатып йөргәндә, безнең авылның бер кызы кунакта булган. Ул кемнең киемнәре икәнен аңлап бабасына әйткән. Ә бабасы халыкны җыеп, сәнәк, балталар белән коралланып, үтерүчеләрне тотып милициягә тапшырганнар.

Сугыш вакытында урлашу да күп булган. Безнең ашлык сараеның бер почмагын җимереп барлы-юклы игенне алып чыктылар, сарыкны алып киттеләр.

Кызык хәлләр дә булгалаган. Безнең авылда ике егет күрше булганнар. Берсе өйләнгән һәм күршесенә «Бүленеп башка чыгам, авыл советы иртәгә килеп мөлкәтне бүләләр»,-дип әйткән.

Икенче көнне иптәш егете «Соң дустым, сиңа нинди әлеш чыкты?», — дип сорагач, «Хаты-ы-ы-ын», — дип җавап биргән шатланып. Аякта чабата, өйдә коры сәке, мал сарае — буш, бүлер нәрсә юк. Кызык та, кызганыч та.

Кайберәүләр, сугыш диеп тормаганнар, кеше алдап мал тапканнар. Бер абый нишләргә белмичә кешеләрне «өшкерергә» мәҗбүр булган. «Тыны бик килешә, дәвалы»,-дигән даны таралган. Берва-кытны рус авылына алып киткәннәр үзен. Иптәшкә дусын да алып барган. Абый көйләп «өшкерә» башлаган: «Төртенсәң ярар иде,

Дөмексәң ярар иде
тфү, тфү.
Син төртенсәң дөньяда,
Бер кяфер кимер иде
тфү, тфү».

Шул сүзләрне тупсада утырган иптәше ишеткәч, аптырап калган. Аңлап алгач эшнең нәрсәдә икәнен, кычкырып көлә башлаган.

«Көлмә, көлмә көлдерәсең,
Бер пот оннан калдырасың
тфү, тфү.
Көләсең килсә чыгып көл,
Көлеп туйгач керерсең
тфү, тфү»

— диеп, эшен җитди генә тәмамлаган. «Бик тырышып эшләгән» өчен аларга бер пот он биреп, пар атлар җигеп өйләренә кайтарып куйганнар.

Кайбер хатын-кызлар «көмешкә» ясап, ирләрне эчереп, йортта эшләрен эшләткәннәр. Чөнки сугыштан соң ир-ат булмаган йортлар бик күп булды. Көмешкә саткан өчен кайберәүләрне өч елга төрмәгә дә утырттылар. Халык эчкечегә салышты.

Бу фаҗигалар яңадан кабатланмасын иде.

**Сәмига ХУРАМШИНА,**
**Красногорка авылы,**
**Әсәкәй районы.**

# В честь погибших воинов

Две мемориальные доски установлены недавно на здании Наурузовской средней школы, Пономаревского района. Установлены они в честь выпускников Ильвира Минвалеевича Кутуева и Марата Зайнулловича Ниязмуллина, погибших на Северном Кавказе. Памятные знаки появились благодаря инициативе вокальной группы « Зеленые береты» из города Уфы. Она объединила бывших участников военных действий в горячих точках. Защитники отечества в свое время дали обещание сохранить в истории память о погибших однополчанах и сослуживцах. Свои обязательства они выполняют, устанавливая Доски и организовывая концерты... Всего за 10 лет деятельности, ими открыты уже 1300 Знаков, в том числе в Оренбуржье — 130 .И на этот раз, они не отошли от установленной традиции.

На территории школы состоялся митинг, посвященный торжественному открытию этих памятных знаков. В мероприятии приняли участие не только учащиеся, пришли также жители села. После митинга, торжественным шествием, участники направились к кладбищу, к могилам солдат, где возложили венки.

Заключительным этапом мероприятия стал концерт, поставленный « Зелеными беретами».Артисты, в своих военных формах со знаками отличия и наградами, выступили с патриотическими песнями, исполнив их на татарском и русском языках.

**И.СУЛЕЙМАНОВА,**
**Пономаревский район**

# Традициям верны

На днях, учащиеся 9 класса Дюсметьевской школы посетили музей, открытый в сельском клубе. В этом уголке истории, хранится память о героическом прошлом наших предков. Входишь в музей и как бы погружаешься в атмосферу тех лет, когда смешались боль и ужас, смерть и кровь, подвиг и бессмертие. Перед нами фотографии, документы, воспоминания участников войны. Что помешало фашистам победить нас? Ответ очевиден: массовый героизм наших войск, их ожесточенное сопротивление, упорство, величайший патриотизм. Моральной основой героизма, является сознательное подчинение личных интересов — общим. Чем выше цель народа — тем величественней героизм. У всех советских людей были общие интересы, единство целей, что и предопределяло единство действий.

Во время экскурсии библиотекарь Ф.Кабишева рассказала нам о тяжелой судьбе тружеников тыла и фронтовиков, прошедших всю войну. Многое узнали о жизни односельчанина Г.Г.Ягофарова. В юные годы, он работал в колхозе, потом был призван в армию, где и застала его война. Воевал он простым солдатом, на передовой. Был несколько раз ранен.За боевые заслуги награжден двумя орденами и медалями. Его супруга Мадина апа в годы войны работала в колхозе на тракторе, потом стала первой девушкой — комбайнером. Поженились после войны, вырастили 4 детей. Всю жизнь трудились в колхозе, стали ветеранами труда.

Следующая « страница» музея — быт села. Мы познакомились с орудиями труда, посудой, одеждой. Каждый экспонат имеет свою историю. Восхитили мастерство и трудолюбие нашего народа.

**Д.МАСАГУТОВА,**
**ученица 9 класса,**
**Пономаревский района.**

## ТЕКСТЫ ПОПУЛЯРНЫХ ТАТАРСКИХ ПЕСЕН

## Нигә яна йөрәгем?

Сандугачлар ияләшкән
Су эчәргә миләштән.
Сагынуларым бетәр әле
Сине күреп сөйләшсәм.

Уф, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем.
Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?!

Агыйделгә басма салдым
Каенын сайлап кына.
Яннарыңа барыр идем
Кош булып сайрап кына.

Уф, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем.
Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?!

Агыйдел суы тирбәлә
Уртасында сал булса.
Суга салсаң, калкып чыгар
Безгә насыйп яр булса.

Уф, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем.
Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?!

Агыйделкәйне кичкәндә
Жырлыйм ишкәк ишкәндә.
Өзелә үзәк, яна йөрәк
Җаныем искә төшкәндә.

Уф, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем.
Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?!

## Җидегән чишмә

Җидегән чишмәләрдә җиде улак,
Челтер-челтер ага көмеш су.
Көмеш сулар ага, кошлар сайрый,
Шул чакларда бигрәк ямансу.
Җидегән чишмәләргә йөзек салдым,
Җидегән йолдыз күреп калсын, дип.
Җанкай-җанаш алсын да куансын,
Вәгъдәләрем булып калсын, дип.
Җидегән чишмәләргә чиләк куйдым,
Пар чиләгем тизрәк тулсынга.
Без сөябез, җаный, яр булсынга,
Без йөрмибез вакыт узсынга.
Җидегән чишмәләрнең талы бөгелә,
Акрын искән җәйге җилләргә.
Сез каласыз инде, без китәбез,
Без китәбез ерак илләргә.

## Җаныем, бәгырем

Иртә буран, кич тә буран,
Мамык шәлеңне уран шул,
Мамык шәлеңне уран.
Кигән киемең күрсәм дә,
Җаныем, бәгырем,
Үзең күргәндәй булам.

Ишек алдында йөримен,
Карлар яуса көримен шул,
Карлар яуса көримен.

Синнән башка ямь табалмый,
Җаныем, бәгырем,
Ямансулап йөримен.

Тимер чана карлар яра,
Бу йөрәгем ник яна шул,
Бу йөрәгем ник яна?
Бу йөрәгем белеп яна,
Җаныем, бәгырем,
Сөйгәнем ятка кала.

## ПРОГНОЗ ПОГОДЫ

**23 МАРТА, ВТОРНИК**
Ночью — 0. Днем — 3.
Пасмурно. Осадки.

**24 МАРТА, СРЕДА.**
Ночью — 8. Днем — 5.
Пасмурно. Осадки.

**25 МАРТА, ЧЕТВЕРГ.**
Ночью — 4.Днем — 0.
Пасмурно. Осадки.

**26 МАРТА, ПЯТНИЦА.**
Ночью — 2. Днем — 3.
Пасмурно. Без осадков.

**27 МАРТА, СУББОТА.**
Ночью — 10. Днем — 0.
Пасмурно. Осадки.

**28 МАРТА, ВОСКРЕСЕНЬЕ.**
Ночью — 6. Днем — 3.
Пасмурно. Осадки.

**29 МАРТА, ПОНЕДЕЛЬНИК.**
Ночью — 6. Днем — 1.
Пасмурно. Осадки.

**30 МАРТА, ВТОРНИК.**
Ночью — 5. Днем +1.
Пасмурно. Осадки.

**31 МАРТА, СРЕДА.**
Ночью — 4. Днем — 0.
Пасмурно. Осадки.

## ОБЪЯВЛЕНИЯ

**Уважаемые жители Абдулинского, Асекеевского, Бугурусланского, Матвеевского, Пономаревского, Северного районов!** Продолжается подписка на газету «Туган як. Родной край» с доставкой со следующего месяца. Обратившись в отделение связи или к почтальонам, **вы можете получать газету уже с апреля**. Газета выходит два раза в месяц. **Цена символическая.**

Редакция газеты «Туган як. Родной край» готова на взаимовыгодных условиях **сотрудничать** с **рекламодателями** и по их заказу готовить и публиковать тематические статьи и материалы.

Редакция «Туган як. Родной край» с благодарностью **примет спонсорскую помощь** от организаций и частных лиц для издания газеты. Справки о банковских реквизитах по телефонам **8 (35351) 2-22-81** или **8-93-25-30-73-33.**

**Уважаемые подписчики газеты!** Редакция принимает заявки на публикацию поздравлений, благодарностей и объявлений, в том числе и на татарском языке. Так как газета выходит два раза в месяц, просим делать заявки заблаговременно. Справки по телефонам **8 (353-51) 2-22-81** или **8-93-25-30-73-33.**

## ПРОГРАММА ТНВ

### ТАТАРСТАН (ВРЕМЯ МОСКОВСКОЕ)

### ВТОРНИК
### 23 марта

6:00 Хэерле иртэ!
8:00 Доброе утро!
9:00 Трубач. (2-я серия)
10:00 Жырлыйк эле
10:45 Колкеханэ
11:00 ТВ фондыннан
11:30 Халкым минем...
12:00 Виктория. (140-я серия)
13:00 Один день из жизни войны
13:30 Путешествие вокруг света
14:00 Новости Татарстана
14:15 Хочу мультфильм!
14:30 Кучтэнэч
14:45 Яшьлэр тукталышы
15:15 Мультфильм
15:40 Музыкаль NON-STOP
15:50 ТВ фондыннан
16:45 Татарстан хэбэрлэре
17:00 Виктория. (141-я серия)
18:00 Кучтэнэч
18:15 Хочу мультфильм!
18:30 Новости Татарстана
19:00 Хоккей. (Кубок Гагарина. «Ак Барс» (Казань) — «Металлург» (Магнитогорск))
21:15 Хочу мультфильм!
21:30 Новости Татарстана
22:00 Две сестры-2. (2-я серия)
23:00 Трубач. (2-я серия)
0:00 (Ср) Автомобиль
0:30 (Ср) Путешествие вокруг света
1:20 (Ср) ТВ фондыннан
2:05 (Ср) ТВ фондыннан
2:25 (Ср) Жырлыйк ?ле
3:10 (Ср) Яна елда бергэ булыйк

### СРЕДА
### 24 марта

6:00 Хэерле иртэ!
8:00 Доброе утро!
9:00 Трубач. (3-я серия)
10:00 Ватандашлар
10:30 Тик син генэ...
11:00 Китап
11:30 Яшэсен театр!
12:00 Виктория. (141-я серия)
13:00 Среда обитания
13:30 Путешествие вокруг света
14:00 Новости Татарстана
14:15 Хочу мультфильм!
14:30 Кучтэнэч
14:45 Син — минеке, мин — синеке
15:15 Мультфильм
15:40 З. Исмэгыйлев. «Кодача»
16:45 Татарстан хэбэрлэре
17:00 Виктория. (142-я серия)
18:00 Кучтэнэч
18:15 Хочу мультфильм!
18:30 Новости Татарстана
19:00 Хоккей. (Кубок Гагарина. «Ак Барс» (Казань) — «Металлург» (Магнитогорск))
21:15 Хочу мультфильм!
21:30 Новости Татарстана
22:00 Две сестры-2. (3-я серия)
23:00 Трубач. (3-я серия)
0:00 (Чт) Видеоспорт
0:30 (Чт) Путешествие вокруг света
1:20 (Чт) З. Исмэгыйлев. «Кодача»
2:20 (Чт) Син — минеке, мин — синеке
2:45 (Чт) Китап
3:15 (Чт) Яна елда бергэ булыйк

### ЧЕТВЕРГ
### 25 марта

6:00 Хэерле иртэ!
8:00 Доброе утро!
9:00 Трубач. (4-я серия)
10:00 Кэеф ничек?
11:00 Үткэннэр сагындыра
11:30 Туган жир
12:00 Торжественная церемония вступления в должность Президента Республики Татарстан Р. Н. Минниханова
14:00 Новости Татарстана
14:15 Хочу мультфильм!
14:30 Кучтэнэч
14:45 Мэктэп
15:00 Мультфильм
15:35 Музыкаль тэнэфес
15:50 ТВ фондыннан
16:45 Татарстан хэбэрлэре
17:00 Виктория. (143-я серия)
18:00 Кучтэнэч
18:15 Хочу мультфильм!
18:30 Новости Татарстана
19:00 Огни большого города. (21-я серия)
20:00 Татарстан хэбэрлэре
20:30 Туган жир
21:00 Кучтэнэч
21:15 Хочу мультфильм!
21:30 Новости Татарстана
22:00 Репортаж с торжественной церемонии вступления в должность Президента Республики Татарстан Р. Н. Минн
0:00 (Пт) Видеоспорт
0:30 (Пт) Огни большого города. (21-я серия)
1:20 (Пт) З. Исмэгыйлев. «Кодача»
2:00 (Пт) Сэхэнэ моннары
2:30 (Пт) Р.Жиһаншина. «Улларым»
5:50 (Пт) Жомга вэгазе

### ПЯТНИЦА
### 26 марта

6:00 Хэерле итртэ!
8:00 Доброе утро!
9:00 Концерт. («Оныта алмыйм...»)
10:00 Мэдэният доньясында
11:00 Татар халык жырлары
11:20 Жомга вэгазе
11:30 Нэсыйхэт
12:00 Виктория. (143-я серия)
13:00 Путь
13:15 НЭП
13:30 Путешествие вокруг света
14:00 Новости Татарстана
14:15 Хочу мультфильм!
14:30 Кучтэнэч
14:45 А. Алиш. «Сертотмас урдэк»
15:35 Музыкаль тэнэфес
15:40 КВН-фестиваль
16:45 Татарстан хэбэрлэре
17:00 Хоккей. (Кубок Гагарина. «Ак Барс» (Казань) — «Металлург» (Магнитогорск))
19:15 Новости Татарстана
19:45 Хочу мультфильм!
20:00 Татарстан хэбэрлэре
20:30 Син — минеке, мин — синеке
21:00 Кучтэнэч
21:15 Хочу мультфильм!
21:30 Новости Татарстана
22:00 Ангел
23:40 Джазовый перекресток
0:10 (Сб) Ангел-2: месть ангела
1:45 (Сб) Э. Баянов. «Зэнгэр кынгыраулар»

### СУББОТА
### 27 марта

6:00 Татарстан хэбэрлэре
6:15 Новости Татарстана
6:45 Путь
7:00 Sина Миннэн Sэлам
9:00 ТИН-клуб
9:30 Созвездие — 2010
11:00 Мужское дело
11:30 Видеоспорт
12:00 Адымнар
12:30 Яшэсен театр!
13:00 Ач, шигърият, серлэренне
13:15 Концерт. (Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дэулэт ансамбле)
15:00 Беренче театр
16:00 Канун. Парламент. Жэмгыять
16:25 Профсоюз — союз сильных
16:40 Песни военных лет
17:00 Лапушки
18:00 Мультфильмы
18:30 Один день из жизни войны. (Фильм 5-й — «Переделкино» на Каме»)
19:00 Среда обитания
19:30 Концерт. («Оныта алмыйм...»)
20:00 Татарстан. Атналык кузэту
20:30 Жырлыйк ?ле
21:15 Страхование сегодня
21:30 Новости Татарстана. В субботу вечером
22:00 Братья-сестры, соперники-соперницы
23:40 Бои по правилам TNA
0:00 (Вс) Ночной музыкальный канал
1:00 (Вс) В кольце смерти
3:30 (Вс) Там, где скрыта тайна

### ВОСКРЕСЕНЬЕ
### 28 марта

7:00 Sина Миннэн Sэлам
9:00 Урмай моны — 2010
9:45 Мэктэп
10:00 Тамчы-шоу
10:30 Яшьлэр тукталышы
11:00 Баскет-ТВ
11:30 Автомобиль
12:00 Ватандашлар
12:30 Татарлар
13:00 Сугыш чоры жырлары
13:30 Мэдэният доньясында
14:30 Елмай!
15:00 Илһам булганда...
16:00 Закон. Парламент. Общество
16:30 Мужское дело
17:00 Лапушки
18:00 Мультфильм
18:15 Санаторий «Бакирово»
18:30 7 дней
19:30 Экэмэт кэмит
20:00 Кэеф ничек?
21:00 Батырлар
21:20 Дорога без опасности
21:30 7 дней
22:30 Видеоспорт
23:00 Легенда Люси Кис
0:40 Супружество
2:25 (Пн) Сугыш чоры жырлары


ТУГАН ЯК РОДНОЙ КРАЙ

**E-MAIL:**tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

ГАЗЕТА ОТПЕЧАТАНА В БУГУРУСЛАНСКОЙ ТИПОГРАФИИ.
461600, г.Бугуруслан, ул.Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**